**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422635 Лаишевский район, с. Атабаево
Ул.Молодежная ,д. 1,
тел, факс: 8(84378)-4-87-41
E-mail Atab.La@tatar.ru

**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

422635 Лаеш районы, Атабай авылы
Яшьлэр урамы , 1нче йорт
тел, факс: 8(84378)-4-87-41
E-mail Atab.La@tatar.ru

**2024елның 29 ноябре** **17 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2021 елның 21 апрелендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, «Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 21 апрелендәге 9 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе» нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 пунктның 3 абзацына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Бирелгән ташламаларны түләүчеләр тарафыннан таләп ителгәнлекне бәяләүне уздыру максатларында, Башкарма комитет тарафыннан әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән чагыштырманың минималь күрсәткечне билгеләнергә мөмкин, бу очракта ташлама кирәк дип танылачак».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Атабай**
**авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Р И. Билялов**